**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ**
**(III чакырылыш)**

егерме җиденче утырыш

**КАРАРЫ**

28 март 2019 ел **№ 170** Теләче авылы

Теләче муниципаль район Советының 2011 елның 30 декабрендәге 85 санлы «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясына туры китереп, җир участокларын бушлай алырга хокуклы гражданнар исемлеген әзерләү тәртибе турында»гы, 2012 елның 14 апрелендәге 97 санлы «Өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнарга җир участоклары бирү турында карар кабул итү тәртибе турында»гы карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасының «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүләре турында һәм Россия Федерациясенең кайбер законнар актына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон кабул ителү уңаеннан Татарстан Республикасының кайбер законнар актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2018 елның 22 декабрендәге 114 санлы законына туры китереп, Теләче муниципаль районы Советы **карар кабул итте:**

1. Теләче муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясына туры китереп, җир участокларын бушлай алырга хокуклы гражданнар исемлеген әзерләү тәртибе турында»гы 2011 елның 30 декабрендәге 85 санлы карарына (2014 елның 03 октябрендәге 223 санлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясына туры китереп җир участогын бушлай алырга хокуклы гражданнар исемлеген әзерләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 3 пункттагы “дача төзелеше” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 17 пункттагы “дача төзелеше” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 18 пункттагы “дача төзелеше” сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 19 пункттагы “дача төзелеше” сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Теләче муниципаль районы Советының «Өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнарга җир участоклары бирү турында карар кабул итү тәртибе турында»гы 2012 елның 14 апрелендәге 97 санлы карарына (2018 елның 21 ноябрендәге 152 санлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. Өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнарга җир участоклары бирү турында карарлар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 3 пункттагы “дача төзелеше” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 20 пункттагы “дача төзелеше” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 22 пунктның икенче абзацындагы “дача төзелеше” сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

4. Карар гамәлдәге законнар нигезендә көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Башлыгы И. Ф. Зарипов